Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ
Центр истории и теории национального
образования им. Х.Фаезханова

# ПРЕПОДАВАНИЕ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ В СИСТЕМЕ СРЕДНЕГО И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ:

## ИСТОРИЯ, СОВРЕМЕННОСТЬ И ПЕРСПЕКТИВЫ

Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения ***Каюма Насыри***

Казань – 2015

УДК 37.02
ББК 74.03
П 72

**Научный редактор:**
кандидат педагогических наук *Гибатдинов М.М.*

**Составители:**
кандидат педагогических наук *Муртазина Л.Р.*,
кандидат филологических наук *Абызова Р.Р.*

**Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы.** Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – 184 с.

**ISBN 978-5-94981-199-3**

© Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015

УДК 374.7

# КАЮМ НАСЫЙРИ ИНСТИТУТЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Хөснетдинов Рәсим Рәхимҗан улы,***
*PhD, Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*knikazan@gmail.com*

Мәкаләдә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында ачылган К. Насыйри институтының Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә татар телен укыту һәм татар мәдәниятен пропагандалау өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртыла.

***Төп төшенчәләр:*** Каюм Насыйри институты, Каюм Насыйри, татар теле.

2014 елда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасы нигезендә, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында халыкара Каюм Насыйри институты эшли башлады. Мәркәзе Казан шәһәрендә урнашкан әлеге фән һәм белем бирү үзәге[1] үз эшен чит төбәкләрдә ачылган белем бирү һәм мәдәният үзәкләре аша алып барачак.

Каюм Насыйри институтының чит төбәкләрдә ачылган белем бирү һәм мәдәният үзәкләрендә татар теле курслары, төрле мәдәни чаралар, фән буенча киңәшләр, «Ана теле» татар телен онлайн өйрәтү мәктәбе дәресләренә катнашу ысуллары, татар теленнән халыкара олимпиадага әзерлек алып бару, 2014–2020 елларга кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан

[1] Татар телендә тулы исеме: Югары профессиональ белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе «Казан (Идел буе) федераль университеты» Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Каюм Насыйри институты» фән һәм белем бирү үзәге. Татар телендә кыскартылган исеме: Каюм Насыйри институты.

Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасы проектларын тормышка ашыру алымнары һ.б. чаралар үткәреләчәк. Әлеге үзәкләрдә шулай ук Татарстан халыклары телләрен үстерү кысаларында рус теленнән дә төрле фәнни-гамәли консультацияләр каралган.

Татарстан Республикасы ярдәме белән Каюм Насыйри институты үзәкләренә куелган заманча җиһазлар университет укытучыларына, студентларга, үзәктә шөгыльләнүчеләргә Казан университеты галимнәре, язучылар, студентлар белән элемтәгә керү, татар һәм рус телләреннән киңәшләр, сорауларга җаваплар алу мөмкинлеген бирәчәк, ә Казан университеты студентлары һәм мөгаллимнәре үзәкләрдәге рус, казах, төрек һәм үзәкләрдәге башка хезмәттәшләренең дәресләрен тыңлый алачак, шулай ук бу җиһазлар ярдәмендә төрле видео-конференцияләр үткәрергә мөмкин булачак.

Үзәкләр ел саен Татарстан Республикасы нәшриятларында басылып чыккан 30 төрдәге (һәрберсе 10 ар данәдән) яңа китап, методик кулланмалар, укыту әсбаплары, сүзлекләр, дәреслекләр белән тәэмин ителәчәк.

Каюм Насыйри институты кебек тел өйрәтү, мәдәният таныту үзәкләре дөньякүләм билгеле булсалар да, алар күп түгел. Милли телләрне, милли мәдәниятне өйрәнү үзәкләрен булдырган институтларга үрнәк буларак берничә дистә ел Германиядә – Гете, 2009 елда Төркиядә – Юныс Әмре, рус теле буенча Пушкин, кытай теле буенча Конфуций, испан теле өлкәсендә Сервантес институтларын атарга була. Мәсәлән, дөньяда Сервантес институтының испан телен, испан мәдәниятен өйрәтүче 77 үзәге эшләве дә мәгълүм.

Каюм Насыйри институты үз эшчәнлегендә дөньяда танылган әлеге инстиутларның тәҗрибәләрен өйрәнә. Программа буенча һәр ел саен чит төбәкләрдә Каюм Насыйри институтының 2–3 белем бирү һәм мәдәният үзәкләрен ачу күздә тотыла. 2014 елда беренче булып Мәскәү һәм Астана шәһәрләрендә шундый үзәкләр ачылды.

Татарстаннан читтә, Россия Федерацисендә ачылган беренче белем бирү һәм мәдәният үзәге 2014 елның 17 декабрендә Мәскәү шәһәрендә Муса Җәлил исемендәге 1186 нче татар этнокомпонентлы мәктәптә урын алды[2].

---

[2] Мәскәүдәге Каюм Насыйри Институты белем бирү һәм мәдәният үзәгенең методисты (җитәкчесе һәм укытучысы) итеп мәктәптә 6 ел татар

Татарстан хөкүмәте, Мәскәүдәге мәгариф җитәкчеләре һәм татар оешмалары үзәк ачылу вакыйгасына зур игътибар бирде. Татарстанның дәүләт шурасы рәисе Ф. Мөхәммәтшин үзенең чыгышында: «Бу институтның беренче үзәген Мәскәүдә ачу безнең өчен бик мөһим. Һәр халык үзенең телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калырга тырыша. Без аңа зур игътибар бирәбез. Үз ягыбыздан без бу юнәлештә ярдәм итеп торачакбыз. Ләкин эш акчада гына түгел, туган телне өйрәнү, белү һәр кешенең күңелендә, җанында булырга тиеш», – диде. Р. Җамалетдиновның: «Без бу үзәкне бөтен дөньяга таралган татарларны берләштерү, туган тел, мәдәниятне аларга җиткерү теләге белән ачтык. Каюм Насыйри исеме һәр татарга да таныш. Ул бөтен гомерен укытуга, мәгарифкә багышлаган. Билгеле мәгърифәтче. Ул укытучы да, галим дә....», – дигән сүзләренә кушылып, Э. Фәттахов бу үзәкнең эше өчен Татарстаннан 164 миллион акча бүлеп бирелгәнен әйтте.

Бу институтның Каюм Насыйри исеме белән аталуында тирән мәгънә бар. Чөнки К. Насыйри язучы да, галим дә, укытучы да, тәрбияче дә. Бүгенге көндә К. Насыйри исемен популярлаштыру мөһим. Әлегәчә педагог-галимгә багышланган әдәби әсәрләр юк, бары тик Ә. Фәйзинең «Тукай» романында гына К. Насыйри сурәтләнгән бер күренеш бар (Анда Каюм Насыри укытыр өчен балаларны җыеп йөри. Кечкенә Тукайны очратып, аңа карандаш бүләк итә).

2014 елның 19 декабрендә Казахстан Республикасы Астана шәһәрендә урнашкан Н.Л. Гумилев исемендәге Евразия милли университетында К. Насыйри исемендәге белем бирү һәм мәдәният үзәге ачылды[3].

300 мең татар яшәгән Казахстан Республикасы һәм 10 мең татарлы Астана шәһәрендә татар теле өйрәнү үзәгенең ачылуы татарлар тормышында гына түгел, ике милләт, ике дәүләт арасында зур вакыйга итеп кабул ителде. Ачылыш тантанасына Казахстан ягыннан һәм татар җәмәгатьчелегеннән күренекле вәкилләр катнашты.

---

теле укытучысы булып эшләгән, педагогика өлкәсендә мактаулы исемнәргә лаек Ләлә Фуат кызы Сәетова билгеләнде.

[3] Астана шәһәрендәге Каюм Насыйри Институты белем бирү һәм мәдәният үзәгенең методисты (җитәкчесе һәм укытучысы) итеп филология фәннәре кандидаты Ләйсән Хәбир кызы Шәяхмәтова билгеләнде.

1996 елда Казахстан президенты Н. Назарбаев фәрманы белән ачылган Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты 2000 елдан бирле халыкара югары уку йорты дәрәҗәсенә ия, 12 факультетта 100дән артык чит ил мөгаллимнәре укыта. Бу үзәкнең Евразия милли университетытында ачылуының төрле сәбәпләре бар; беренчедән КФУ һәм АМУ университетлары арасында имзаланган меморандумның гамәлдә булуы, шул меморандум кысаларында каралган чараларның да күпчелеген шушы үзәк аша башкарылырга мөмкинчелек тудыруы булса, икенчедән, бу университетта Пушкин исемендәге рус теле, Конфуций исемендәге кытай телен, Г. Алиев исемендәге әзербайҗан телен өйрәнү, поляк теле һ.б үзәкләр эшләп килә. Университетның бу өлкәдә тәҗрибәсе зур.

Евразия университетының филология факультеты базасында урнашкан Үзәктә, беренче чиратта, һәр теләгән кеше татар теле өйрәнә алачак. Бигрәк тә чит җирләрдә туган тел өйрәнергә теләге булган милләттәшләребез, казах филологиясе өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып баручы галимнәр, милли төркемнәрдә укучы студентлар татар теле курсларына теләп йөрерләр дип уйлыйбыз. Шулай ук үзәктә К. Насыйри, татар теле, мәдәнияте белән бәйле материаллар, Татарстан-Казахстан мөнәсәбәтләрен чагылдырган фәнни хезмәтләр, татар-казах тормышына багышланган әдәби әсәрләр дә урын алачак.

Татар теленә өйрәтү һәм мәдәниятен таныту өчен хөкүмәт ярдәме белән Казан университетында оештырылган Каюм Насыйри институты, күренекле педагогыбыз Каюм Насыйри кебек үк, үз теленә, милләтенә хезмәттә уңышларга ирешер, татар телен Татарстаннан еракта яшәүче халкыбызга һәм башка милләтләргә өйрәтүдә өлеш кертеп, ата-бабаларыбызның күп гасырлык бай мәдәни мирасын танытып, тынычлык, иминлек һәм үзара татулыкка белем юлы белән хезмәт итәр халкыбызга, милләтебезгә хезмәт итәр дип ышанабыз.

**Электрон ресурслар**

1. Ана теле, татар телен онлайн өйрәнү мәктәбе: http://anatele.ef.com (15.03.2015).
2. Бөтендөнья татар конгрессының интернет сәхифәсе: http://tatar-congress.org (15.03.2015).
3. Каюм Насыйри Институты интернет-сәхифәсе: http://kpfu.ru/philology-culture/ikn (15.03.2015).
4. Н.Л.Гумилев исемендәге Евразия милли университеты: http://www.enu.kz (15.03.2015).

## THE ACTIVITIES OF THE KAYUM NASYRI INSTITUTE IN THE TEACHING TATAR LANGUAGE

***Khusnutdinov Rasim Rakhimzyanovich,***
*PhD,*
*Kazan (Volga region) Federal Univercity,*
*knikazan@gmail.com*

This paper presents the activities of the new Kayum Nasyri Institute in education of Tatar language and Tatar culture in abroad.

***Keywords:*** Kayum Nasyri Institute, Kayum Nasyri, Tatar language.